ГЛАВА АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.07.2026 пгт Аксубаево № 32

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Сөнчәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында " 25.03.2025 №33-ФЗ Федераль законы, Аксубай муниципаль районы Уставына таянып Аксубай муниципаль районы башлыгы КАРАРы:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Сөнчәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы составын-коллегиаль киңәшмә органын расларга:

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе С. Ю. Зайцев;

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары И. И. Исламов;

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы О. А. Тимкина;

- Аксубай муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе М. Ә. Габдрахманов;

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге башлыгы А.В. Калуков.

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга гавами тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү чорын - кызыксынучы затларга аларны үткәрү турында хәбәр иткән вакыттан алып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр билгеләргә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы проект басылып чыккан көннән алып бер айдан да артмый.

5. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган җәмәгать фикер алышуларының башлануы турында хәбәр әзерләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.rn) һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (https://aksubayevo.tatarstan.ru/)бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар үтәлешен тикшерел торуны үземдә калдырам.

Район башлыгы А.М.Мингулов